**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«01» 04 2021 ел Яр Чаллы №1009

2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча ярдәмче программага үзгәрешләр кертү турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 28 декабрендәге Пр-2665 номерлы боерыгы белән расланган 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплексы планына таянып, һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш буенча профилактик эшчәнлекне көчәйтү, шулай ук район территориясендә террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркемнең 2021 елның 26 февралендәге 17 нче утырышы беркетмәсе, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 1 декабрендәге 4634 номерлы карары белән расланган 2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча ярдәмче программаның 1 кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә ярдәмче программа чараларын башкару буенча оештыру-гамәли чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.
3. Тукай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджет формалаштырганда, ярдәмче программаны гамәлгә ашыру срокларын исәпкә алып, ярдәмче программа чараларын башкаруга район бюджеты акчалары хисабына финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин